ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

17.12.2024 г.Казань № 558-75/тэ-2024

Баулы муниципаль районы кулланучыларына «Таткоммунэнерго» республика җитештерү берләшмәсе» акционерлык җәмгыяте тарафыннан җибәрелә торган җылылык энергиясенә (егәрлеккә) 2025 елга тарифлар билгеләү турында

«Җылылык белән тәэмин итү турында» 2010 елның 27 июлендәге 190-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә бәя билгеләү турында» 2012 елның 22 октябрендәге 1075 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә җайга салынулы бәяләрне (тарифларны) хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 13 июнендәге 760-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсенең 17.12.2024 ел, №34-ПР утырыш беркетмәсе нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «Таткоммунэнерго» республика җитештерү берләшмәсе» акционерлык җәмгыяте (алга таба – «Таткоммунэнерго» республика җитештерү берләшмәсе» АҖ) тарафыннан Баулы муниципаль районы кулланучыларына җиткерелә торган җылылык энергиясенә (егәрлегенә) әлеге карарның 1 кушымтасына туры китереп, календарь буенча бүленгән тарифлар билгеләргә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән тарифлар 2025 елның 1 гыйнварыннан 2025 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис А.С.Груничев

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 17.12.2024 № 558-75/тэ-2024 карарына кушымта

Баулы муниципаль районы кулланучыларына «Таткоммунэнерго» РҖБ» АҖ тарафыннан җибәрелә торган җылылык энергиясенә (егәрлеккә) 2025 елга календарь буенча бүленгән тарифлар

| т/с | Муниципаль берәмлекнең, җайга салынулы оешманың аталышы, тариф төре | Ел | су | Басым астында сайланма пар | | | | Әче һәм редукциял әнгән пар |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 1,2 башлап 2,5 кг/см$^2$ кадәр | 2,5 башлап 7,0 кг/см$^2$ кадәр | 7,0 башлап 13,0 кг/см$^2$ кадәр | 13,0 кг/см$^2$ югары | |
| | Баулы муниципаль районы | | | | | | | |
| 1 | «Таткоммунэнерго» республика җитештерү берләшмәсе» АҖ | | | | | | | |
| 1.1 | Тоташтыру схемасы буенча тарифлар дифференциацияләнмәгәндә, – кулланучылар өчен | | | | | | | |
| | бер ставкалы, сум/Гкал | 01.01.2025 башлап 30.06.2025 кадәр | 2 284,35 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2025 башлап 31.12.2025 кадәр | 2 675,71 | - | - | - | - | - |
| 1.2 | Халык (тарифлар өстәмә хак салымын исәпкә алып күрсәтелгән) <*> | | | | | | | |
| | бер ставкалы, сум/Гкал | 01.01.2025 башлап 30.06.2025 кадәр | 2 741,22 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2025 башлап 31.12.2025 кадәр | 3 210,85 | - | - | - | - | - |

<*> Россия Федерациясе Салым кодексының 168 статьясындагы 6 пунктын гамәлгә ашыру максатларында аерып чыгарыла.

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф карарларын кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге